| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**05.04.2023** № **04-05-45**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә язылган «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» 04-14-49 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

2023 нче елның 26 нчы гыйнварында кабул ителгән «Татарстан Республикасының Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 1-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2023 нче елның 4 нче февралендә чыгарылган «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) Администрациясе турында» УП-68 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасының иң югары вазифа башкаручы затының вазифасы исеменең үзгәрүенә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә язылган «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт

проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» 04-14-49 номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 нче елның 24 нче мартында язылган 04-14-40 номерлы, 2019 нчы елның 12 нче августында язылган 04-05-94 номерлы, 2021 нче елның 5 нче августында язылган 04-05-94 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пункттагы «Татарстан Республикасы Президентының» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләр белән, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» дигән сүзләрне «республика башкарма хакимият органнары» дигән сүзләр белән алыштырырга;

3.11 нче пункттагы «Татарстан Республикасы Президентының» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләр белән алыштырырга;

4.4 нче пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенең» дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары И.Г.Багаутдиновка йөкләргә.

Рәис Р.Н.Сабиров